ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.10.2020 Казан шәһәре № 134-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасында этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 3 декабрендәге 228-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасында этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 3 декабрендәге 228-п номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2019 елның 15 апрелендәге 47-од номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эзерләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 маендагы 298 номерлы, «Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү тәртибен раслау турында» 2014 елның 5 маендагы 298 номерлы карарларын үтәү максатында боерык бирәм:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга (кушымтада бирелә) (алга таба – Регламент).»;

3 пунктта «дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга» сүзләреннән алда «хәбәр итеп (ирекле) теркәү буенча» сүзләрен өстәргә;

Әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте кусәтүнең административ регламентын яңа редакциядә расларга (кушымтада бирелә).

2. Ветеринария эшен оештыру бүлегенә әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе сайтында урнаштырырга.

3. Хокук бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми рәвештә бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Г.Г.Мотыйгуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты Баш
ветеринария идарәсенең 2018
елның 3 декабрендәге 228-п
номерлы боерыгы белән
расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты Баш
ветеринария идарәсенең 2020
елның 19 октябрендәге
134-од номерлы боерыгы
редакциясендә)

# Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: этләрнең хуҗалары – торак, хезмәт һәм махсус урыннарда, шулай ук әлеге максат өчен махсус билгеләнгән урыннарда этләр асрый торган гражданнар һәм юридик затлар (алга таба – Мөрәҗәгать итүче).

Дәүләт хезмәте фәнни, фәнни-тикшеренү, медицина оешмалары өчен фәнни тикшеренү объектлары булган этләрне тоту өлкәсендәге мөнәсәбәтләргә кагылмый.

1.3. Әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән затларның мәнфәгатьләрен үз вәкаләтләрен таныклый торган документ нигезендә яки законнар нигезендә Мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүче башка затлар да (законлы вәкилләр) (алга таба – Мөрәҗәгать итүче вәкиле) белдерә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе (алга таба – Идарә) тарафыннан, Мөрәҗәгать итүченең яшәгән яки торган урыны буенча ведомство буйсынуындагы район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре (алга таба – район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсе) аша күрсәтелә.

1.4.1. Ветеринария идарәсенең, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләренең урнашкан урыны, белешмә телефоннары, электрон адреслары әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән.

Идарәнең урнашкан урыны: Казан шәһәре, Федосеев урамы, 36 йорт.

Идарәнең, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләренең эш графигы: шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш, һәр көнне, дүшәмбе-җомга 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала, Идарәнең, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләренең эш сәгатьләрендә.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

1.4.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына кергән Идарәнең рәсми сайты адресы (алга таба – «Интернет» челтәре һәм Идарәнең рәсми сайты): http://guv.tatar.ru., электрон почта адресы: guv.tatar.ru.

1.4.3. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) «Интернет» челтәре аша;

«Интернет» челтәрендәге Идарәнең рәсми сайтында (http://guv.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);http://www.gosuslugi.ru/

2) Идарәгә, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләренә телдән (язмача яки телефон буенча) мөрәҗәгать иткән очракта;

3) Идарәгә, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләренә язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә.

Идарәнең Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» челтәрендә Идарәнең рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы белешмәләрне үз эченә ала;

1.4.4. Идарәнең урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Идарәнең электрон почта адресы турында мәгълүмат Идарәнең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

1.5. Дәүләт хезмәте этне тудыран-туры карау өчен тәкъдим иткәндә күрсәтелә.

1.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Идарәнең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.7. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

административ регламент – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү процессында башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган административ процедураларның (гамәлләрнең) срокларын һәм эзлеклелеген билгели торган законнар нигезендә билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча вәкаләтләр бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт

хакимияте башкарма органының (алга таба – башкарма хакимият органы) норматив хокукый акты;

дәүләт хезмәте – федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы, җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеге, ул дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән вәкаләтләре чигендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең рәсми мөрәҗәгатьләре буенча гамәлгә ашырыла;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять (алга таба – шикаять) – Мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең башкарма хакимият органы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, башкарма хакимият органы вазыйфаи заты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яисә 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмалар яки аларның хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдаланган вакытта аның бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турындагы таләбе;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – дәүләт хезмәте күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган рәсми мөрәҗәгать. Гариза формасы әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торган), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада да, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле рәсми мөрәҗәгать белән яки 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтелә торган, ә дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнар яки муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар белән хезмәттәшлек итү мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка гына, норматив хокукый актларга һәм хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә туры китереп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырыла торган принцип;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләр ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр

эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү | «Татарстан Республикасында хайваннар белән эш итү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 5 маендагы 298 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү тәртибе (алга таба – Тәртип) |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе – ведомство буйсынуындагы район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре аша | Тәртипнең 5 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 10 мартындагы 202 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария |

| | | |
|---|---|---|
| | | идарәсе турындагы нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 3.3.26 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Мөрәҗәгать итүчегә этне теркәү турында таныклык бирү (дубликат бирү, этне теркәү турында таныклыкны алыштыру, этне теркәү исәбеннән төшерү) яисә таныклык бирүдән баш тарту | Тәртипнең 13 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Дәүләт хезмәте Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә, гаризаны кабул итү һәм теркәү мизгеленнән башлап күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә. | Тәртипнең 12, 18, 22, 26 пунктлары |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Этне теркәү турында таныклык бирелгәндә, әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән форма буенча гариза рәсмиләштерелә.<br>Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:<br>эт хуҗасының паспорт күчермәсе (гражданин өчен) яисә юридик затның дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);<br>мөрәҗәгать итүчене салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе, салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп;<br>эт хуҗасы – физик зат (гражданин өчен) исеменнән эш итәргә Мөрәҗәгать итүче вәкаләтләренраслый торган документ;<br>Мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – юридик зат исеменнән (юридик затлар өчен) эш итәргә вәкаләтле булуын раслый торган документ;<br>эткә милекчелек хокукы яки бүтән әйбер хокукы булуын раслый торган документ (булган очракта); | Тәртипнең 11, 17, 21, 25 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | эттә элек ясалган идентификация чаралары (булган очракта) булуы турында мәгълүмат;<br>эткә карата үткәрелгән мәҗбүри профилактик ветеринария чаралары турында мәгълүмат (булган очракта);<br>эт баласы өчен метрика яки эткә нәсел шәҗәрәсе күчермәсе (булган очракта);<br>этнең фотосы (эт хуҗасының теләге буенча).<br>2. Этне теркәү турында таныклык дубликаты бирү турындагы гаризага (әлеге Регламентка 5 нче кушымта) түбәндәге документлар теркәлә:<br>эт хуҗасының паспорт күчермәсе (гражданин өчен) яисә юридик затның дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);<br>мөрәҗәгать итүчене салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе, салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп;<br>эт хуҗасы – физик зат (гражданин өчен) исеменнән эш итәргә Мөрәҗәгать итүче вәкаләтләрен раслый торган документ;<br>Мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – юридик зат исеменнән (юридик затлар өчен) эш итәргә вәкаләтле булуын раслый торган документ;<br>эткә милекчелек хокукы яки бүтән әйбер хокукы булуын раслый торган документ (булган очракта);<br>этне теркәү турында яраксызга чыккан таныклык (булган очракта).<br>3. Этне теркәү турында таныклыкны алыштыру турындагы гаризага (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта) түбәндәге документлар теркәлә:<br>эт хуҗасының паспорт күчермәсе (гражданин өчен) яисә юридик затның дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);<br>мөрәҗәгать итүчене салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе, салым түләүченең идентификация номерын | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтеп;<br>эт хуҗасы – физик зат (гражданин өчен) исеменнән эш итәргә Мөрәҗәгать итүче вәкаләтләрен раслый торган документ;<br>Мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – юридик зат исеменнән (юридик затлар өчен) эш итәргә вәкаләтле булуын раслый торган документ;<br>эткә милек хокукы яки башка әйбер хокукы булуын раслый торган документ (булган очракта).<br>4. Этне теркәү исәбеннән төшергәндә гаризага (әлеге Регламентка 7 нче кушымта) түбәндәге документлар теркәлә:<br>эт хуҗасының паспорт күчермәсе (гражданин өчен) яисә юридик затның дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);<br>Мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – физик зат (гражданин өчен) исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документ;<br>Мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – юридик зат исеменнән (юридик затлар өчен) эш итәргә вәкаләтле булуын раслый торган документ;<br>эткә милек хокукы яки башка әйбер хокукы булуын раслый торган документ (булган очракта). | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны тапшыру тәртибе | Мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри башка түләүләр буенча бурычларның булуы (булмавы) турындагы белешмәләр ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына (Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсендә) (алга таба – Федераль салым хезмәтенең ТР идарәсе).<br>Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз ихтыяры белән дә тапшырырга хокуклы.<br>Әлеге документлар Мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый | Тәртипнең 11 пункты. |

| | | |
|---|---|---|
| | мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Идарә мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче мәртәбә баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:<br>әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы;<br>әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның моңа вәкаләтле булмаган зат тарафыннан тапшырылуы;<br>дөрес булмаган (төгәл булмаган) белешмәләре булган документларның һәм гамәлдәге чоры узган документларның тапшырылуы | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>ике айлык яшенә җитмәгән этне теркәү өчен тәкъдим итү;<br>этне карау өчен күрсәтмәү | Тәртипнең 9, 10 пунктлары |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.<br>Этне теркәгәндә ветеринария хезмәтләре (өстәмә ветеринария хезмәтләре) күрсәтелсә, аларны күрсәткән өчен түләү алына, аның күләме Идарә тарафыннан билгеләнә һәм район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләренең локаль акты белән раслана | Тәртипнең 7 пункты, 8 пункты |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне | Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать иткәндә чиратта көтү вакыты – 15 минуттан артмый. | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Аерым категория мөрәҗәгать итүчеләр өчен чират билгеләнмәгән | камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гариза һәм документлар килгән көнне.<br>Гариза электрон формада ял көнендә килгән очракта – килгән көненнән соңгы эш көнендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, һаваны кондиционерлау системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның да чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:<br>бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;<br>объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, бинага керү һәм объектка керү, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;<br>күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;<br>инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү;<br>хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.<br>2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат- | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>2) Мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>3) дәүләт хезмәте күрсәтү | 210-ФЗ номерлы федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән (шул исәптән тулы күләмдә) файдалану мөмкинлеге яки файдалана алмау | ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы»нда тулы мәгълүмат булу;<br>4) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>5) инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;<br>3) әлеге Регламентны дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бозуларга карата прецендентлар (нигезле шикаятьләр) булу (прецендентларның, шикаятьләрнең Идарәнең, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләренең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гомуми исәбенә карата нисбәте);<br>4) мөрәҗәгать итүченең район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре белгечләре белән үзара хезмәттәшлеге саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>гариза белән документларны почта аша җибәргәндә, – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Мөрәҗәгать итүче белән эшләү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша, дәүләт хезмәтләре һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында күрсәтү каралмаган.<br>Мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге юк.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр | Гаризаны Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша электрон формада тапшыру мөмкинлеге бар (алга таба – Интернет-кабул итү системасы).<br>Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша электрон документ формасында гариза бирү мөмкинлеген тормышка ашырганнан соң, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе электрон рәвештә бирелә | «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты,<br>210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$, $21^2$ статьялары |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә дә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) этне карау һәм аңа идентификация номеры бирү;

5) мөрәҗәгать итүчегә этне теркәү турында таныклык яки таныклык бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү тапшыру;

6) техник хаталарны төзәтү;

7) этне теркәү турында таныклык дубликаты бирү;

8) этне теркәү турындагы таныклыкны алыштыру;

9) этне теркәү исәбеннән төшерү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче Идарәгә, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләренә шәхсән, почта аша, телефоннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша һәм (яки) электрон почта ярдәмендә дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Идарә, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсе белгече шәхсән, телефоннан, электрон почта һәм (яки) хат белән, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, Мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, Мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның рәвеше һәм эчтәлеге буенча Мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, почта, электрон почта, Татарстан Республикасы Хөкүмәте Порталының Интернет-кабул итү системасы аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенә мөрәҗәгать итә.

Гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша мондый мөмкинлек гамәлгә ашырылганнан соң тапшырылырга мөмкин.

3.3.2. Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең килгән корреспонденцияне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи заты:

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат сыйфатында гариза тапшыручының вәкаләтләрен тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган документлар булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, документларны кабул итүдә әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең килгән корреспонденцияне исәпкә алу өчен җаваплы белгече Мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләр барлыгы турында хәбәр итә һәм аңа, баш тарту өчен ачыкланган нигезләр эчтәлеген аңлатып, документларны

кайтарып бирә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә.

Мөрәҗәгать итүче гариза һәм документларны почта (электрон почта) аша җибәргәндә, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең килгән корреспонденцияне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи заты аңа почта (электрон почта) буенча баш тарту өчен нигезләр эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кире кайтара.

Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең килгән корреспонденцияне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи заты:

гаризаны кабул итә һәм терки;

документларны кабул итү датасы һәм вакыты, кергәндә беркетелгән номеры турында тамгалап, гариза күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыра яки почта буенча яки электрон почта (аның ихтыярына карап) аша җибәрә;

район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы затына (алга таба – район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең җаваплы белгече) гариза белән документларны җибәрә;

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең җаваплы белгеченә җибәрелгән гариза, гариза белән документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү, Мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.4. Ведомствоара мөрәҗәгатьләр юллау. Этне карау һәм аңа идентификация номеры бирү. Мөрәҗәгать итүчегә этне теркәү турында таныклык яки таныклык бирүдән баш тарту турында мотивлаштырылган белдерү тапшыру.

3.4.1. Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең җаваплы белгече:

1) әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булу-булмавын тикшерә;

2) электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы) ярдәмендә мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булуы (булмавы) турында белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать җибәрә – Федераль салым хезмәтенең ТР идарәсенә.

3) этне карый;

4) эткә идентификация номеры бирә һәм «Этләрне теркәү журналы»на (әлеге Регламентка 8 нче кушымта) язу терки;

5) ТР Министрлар Кабинетының 298 номерлы карары белән расланган форма буенча этне теркәү турында таныклык (алга таба – таныклык) рәсмиләштерә, бирә һәм «Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы»на (әлеге Регламентка 3 нче кушымта) язу терки.

3.4.1.1. Таныклыкта түбәндәге мәгълүмат күрсәтелә:

1) теркәлгәндә бирелә торган этнең идентификация номеры;

2) эт хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт белеш-

мәләре, аның тору урыны яки яшәү урыны буенча теркәлүе, шулай ук фактта яшәү урыны турында белешмәләр (әгәр хуҗасы булып физик зат торса);

3) юридик затның атамасы һәм урнашкан урыны (хуҗасы булып юридик зат торса);

4) этнең токымы, төсе, кушаматы, махсус билгеләре, этнең электрон мәгълүмат йөрткече (микрочип) булуы турында белешмәләр;

5) эткә карата үткәрелгән мәҗбүри профилактика чаралары турында мәгълүмат;

6) эт асралачак бина яки җир участогы адресы.

Мөрәҗәгать итүчегә бирелгән таныклык турындагы мәгълүмат «Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы»на кертелә (әлеге Регламентка 3 нче кушымта).

3.4.1.2. Әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, мөрәҗәгать итү көнендә район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсе вазыйфаи заты Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен каршылыклар булуы турында, сәбәпләрен күрсәтеп, язмача хәбәр итә һәм документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) шәхси кабул иткәндә – гариза кергән көнне, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең җаваплы белгеченә этне карау өчен күрсәткәндә;

2) гариза, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, почта элемтәсе аша яки электрон документлар рәвешендә («Интернет» челтәре аша) алынган очракта – гариза һәм документлар район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләренә кергән көнне яки район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләренең эш вакыты тәмамлангач алынса, икенче көнне. Гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар электрон документлар формасында ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә алынган очракта – район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләренең ял яки эшләми торган бәйрәм көннәреннән соңгы беренче эш көнендә.

3.4.1.3. Әлеге Регламентның 3.4.1 пункты нигезендә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатькә Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булуы турында мәгълүмат алынган очракта, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләренең җаваплы белгече аңа мондый бурыч булуы турында хәбәр итә.

Процедураның нәтиҗәсе: эткә уздырылган карау, эткә бирелгән идентификация номеры, «Этләрне теркәү журналы»на кертелгән язу, рәсмиләштерелгән һәм Мөрәҗәгать итүчегә бирелгән таныклык, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү.

3.5. Техник хаталарны төзәтү.

3.5.1. Таныклыкта техник хата (язу, басма хаталары, грамматик хаталар) булуы ачыкланган очракта, Мөрәҗәгать итүче район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенә, таныклыкта техник хата булуы турында таныклый торган

документларны теркәп, техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 4 нче кушымта), шулай ук Мөрәҗәгать итүчегә бирелгән таныклык оригиналын район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенә тапшыра.

3.5.2. Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең килгән корреспонденцияләрне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи заты техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм терки һәм аны район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең җаваплы белгеченә җибәрә.

Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең җаваплы белгече тарафыннан таныклыкта техник хата булу факты расланган очракта, Мөрәҗәгать итүчегә яңа таныклык бирелә.

Бирелгән таныклык турындагы мәгълүмат «Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы»на кертелә (әлеге Регламентка 3 нче кушымта).

Техник хата булган таныклыкның оригиналы Мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылмый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хатаны төзәтү турындагы гариза теркәлгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, техник хатасы төзәтеп рәсмиләштерелгән һәм Мөрәҗәгать итүчегә бирелгән таныклык.

3.6. Этне теркәү турында таныклык дубликаты бирү.

3.6.1. Таныклык дубликаты бирү, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, теркәлгән гариза (әлеге Регламентка 5 нче кушымта) нигезендә, элегрәк бирелгән таныклыкны югалту яки аның яраксыз хәлгә килүенә бәйле рәвештә таныклык биргән район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.6.2. Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең килгән корреспонденцияләрне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи заты таныклык дубликаты бирү турындагы гаризаны кабул итә һәм терки һәм аны район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләсенең җаваплы белгеченә җибәрә.

Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең җаваплы белгече таныклык дубликатын рәсмиләштерә һәм Мөрәҗәгать итүчегә тапшыра һәм «Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы»на бирелгән таныклык дубликаты турында язу терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: таныклык дубликаты бирү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, рәсмиләштерелгән һәм Мөрәҗәгать итүчегә бирелгән таныклык дубликаты.

3.7. Этне теркәү турында таныклыкны алыштыру.

3.7.1. Эт хуҗасы алышынган очракта, аның яшәү яки тору урыны үзгәргәндә, шулай ук әлеге Регламентның 3.4.1.1 пунктында күрсәтелгән белешмәләр үзгәргән очракта, Мөрәҗәгать итүче таныклык биргән район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенә этне теркәү турындагы таныклыкны алмаштыру турында гариза (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта) белән мөрәҗәгать итә. Гаризага әлеге Регламентның

2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлә.

Эт хуҗасы алышынган очракта, әлеге гариза белән этнең яңа хуҗасы мөрәҗәгать итә.

3.7.2. Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең килгән корреспонденцияләрне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи заты этне теркәү турындагы таныклыкны алмаштыру турындагы гаризаны кабул итә һәм терки һәм аны район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең җаваплы белгеченә җибәрә.

3.7.3. Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең җаваплы белгече яңа таныклык рәсмиләштерү юлы белән таныклыкны алмаштыра һәм Мөрәҗәгать итүчегә бирә һәм таныклыкны алмаштыру турында «Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы»нда язу терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: таныклыкны алыштыру турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, рәсмиләштерелгән һәм Мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган таныклык.

3.8. Этне теркәү исәбеннән төшерү.

3.8.1. Эт үлгән яки аны хайваннар приютына тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенә этне теркәү исәбеннән төшерү турында гариза (әлеге Регламентка 7 нче кушымта) белән мөрәҗәгать итә. Гаризага әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлә.

3.8.2. Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең килгән корреспонденцияләрне исәпкә алу өчен җаваплы вазыйфаи заты этне теркәү исәбеннән төшерү турындагы гаризаны кабул итә һәм терки һәм аны район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләсенең җаваплы белгеченә җибәрә.

3.8.3. Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең җаваплы белгече «Этләрне теркәү журналы»на (әлеге Регламентка 8 нче кушымта) этне теркәү исәбеннән этне төшерү турында язу терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: этне теркәү исәбеннән төшерү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, этне теркәү исәбеннән төшерү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент һәм дәүләт хезмәте үтәлешенә карата таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларның нигезләмәләре үтәлүенә һәм башкарылуына карата, шулай ук җаваплы затлар тарафыннан карарлар кабул ителүгә агымдагы контрольлек Идарә җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы контрольлек дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү формасында башкарыла.

4.3. Тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы

тикшерүләр эш планнары нигезендә башкарыла. Планнан тыш тикшерүләр Мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча үткәрелә.

4.4. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Идарә, район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсе эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Идарә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсе җитәкчесенә шикаять белдерү хокукына ия.

Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәсе җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Идарә җитәкчесенә бирелә.

Идарә җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты бозылганда;

3) Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документлар яки мәгълүматлар тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны Мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда Мөрәҗәгать итүчедән, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затлар тарафыннан шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Идарәнең (http://guv.tatar.ru) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә, шулай ук Мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче шикаятендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм Мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат яисә дәүләт хезмәткәре карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш

көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең Мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан Мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшы-рылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.7. Әлеге Регламентның 5.6 пунктының 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, Мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә һәм, Мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба Мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, Мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

## Район һәм шәһәр ветеринария берләшмәләре

| Дәүләт учреждениесе исеме | Почта индексы, адресы | коды | Телефон | Эл. почта адресы |
|---|---|---|---|---|
| «Әгерҗе районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422231, ТР, Әгерҗе шәһәре, Ленин урамы, 90 | 85551 | 2-46-29 ф | agryz.vet@tatar.ru |
| «Азнакай районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423300, ТР, Азнакай шәһәре, Профсоюз урамы, 6 | 85592 | 7-22-29 ф | Nailya.Miftahova@tatar.ru |
| «Аксубай районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423060, ТР, Аксубай ш.т.п., Мазелин урамы, 35 | 84344 | 2-71-58 ф | aksu-vet@mail.ru |
| «Актаныш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423740, ТР, Актаныш авылы, Промзон урамы, 8 | 85552 | 3-21-19 ф | akt.vet@tatar.ru |
| «Алексеевск районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422900, ТР, Алексеевск ш.т.п., Чистай урамы, 5 | 84341 | 2-61-35 ф | Tatyana.Petuhova@tatar.ru |
| «Әлки районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422870, ТР, Базарлы Матак авылы, Дорожная урамы, 8 | 84346 | 2-02-50 ф | alkeevo.vet@rambler.ru |
| «Әлмәт районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423450, ТР, Әлмәт шәһәре, Совет урамы, 3 | 8553 | 32-81-30 | Alm.Gvo@tatar.ru |
| «Апас районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422350, ТР, Апас ш.т.п., Совет урамы, 5 | 84376 | 2-15-63 | apasrgvo@rambler.ru |
| «Арча районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422002, ТР, Арча шәһәре, Комсомол урамы, 80 | 84366 | 3-10-93 ф | Arsk.Vettatar@tatar.ru |
| «Әтнә районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422750, ТР, Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 1б | 84369 | 2-21-27 | Said.Ahmadullin@tatar.ru |
| «Баулы районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423931, ТР, Баулы шәһәре, Вахитов урамы, 10 | 85569 | 5-77-38 ф | Marina.Usmanova@tatar.ru |
| «Балтач районы | 422250, ТР, Балтач | 84368 | 2-62-57 | Salyahova.Nuriya@tatar.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | авылы, Комсомол урамы, 44 | | | |
| «Бөгелмә районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423230, ТР, Бөгелмә шәһәре, Залаков урамы, 2г | 85594 | 9-11-35 ф | Tatyana.Mosencova@tatar.ru |
| «Буа районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422430, ТР, Буа шәһәре, Р. Люксембург урамы, 83 | 84374 | 3-24-04 | Fanciya.Nigmatullina@tatar.ru |
| «Югары Ослан районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422570, ТР, Югары Ослан авылы, Чехов урамы, 66 | 84379 | 2-16-38 ф | w-uslwet@mail.ru |
| «Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422701, ТР, Биектау авылы, Үзәк урамы, 4 | 84365 | 3-15-09 ф | Alfiya.Zakirova@tatar.ru |
| «Чүпрәле районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422470, ТР, Иске Чүпрәле авылы, Сабантуй мәйданы, 14 | 84375 | 2-23-77 ф | Guv.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| «Алабуга районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423604, ТР, Алабуга шәһәре, Азин урамы, 155 | 85557 | 7-03-37 ф | Elabuga.rgvo@tatar.ru |
| «Зәй районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423522, ТР, Зәй шәһәре, Толстой урамы, 85 | 85558 | 6-60-18 ф | Hurshida.Muhamethano@tatar.ru |
| «Зеленодольск районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422551, ТР, Зеленодольск шәһәре, Столичная урамы, 64 | 84371 | 3-76-21 ф | zel.dol.vet@rambler.ru |
| «Кайбыч районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422330, ТР, Олы Кайбыч авылы, Гыйсмәтуллин урамы, 5 | 84370 | 2-12-26 ф | Saniya.Gaynullina@tatar.ru |
| «Кама Тамагы районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422820, ТР, Кама Тамагы ш.т.п., Вахитов урамы, 4 | 84377 | 2-12-70 ф | Ilgamiya.Mannatova@tatar.ru |
| «Кукмара районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422110, ТР, Кукмара шәһәре, Толстой урамы, 1 | 84364 | 2-72-00 ф | kukmor.vet@tatar.ru |
| «Лаеш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422610, ТР, Лаеш шәһәре, Урожайная урамы, 1 | 84378 | 2-70-01 ф | Aniya.Fatyhova@tatar.ru |
| «Лениногорск районы дәүләт | 423250, ТР, Лениногорск шәһәре, | 85595 | 6-17-83 ф | Lvet2008@rambier.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| ветеринария берләшмәсе» ДБУ | Колхоз урамы, 14 | | | |
| «Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422191, ТР, Мамадыш шәһәре, Пугачев урамы, 25 | 85563 | 3-18-35 ф | Ilyas.Gaptrahimov@tatar.ru |
| «Менделеевск районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423650, ТР, Менделеевск шәһәре, Гунин урамы, 1 | 85549 | 2-11-72 ф | mend-vet@mail.ru |
| «Минзәлә районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423700, ТР, Минзәлә шәһәре, Пролетар урамы, 60 | 85555 | 3-13-05 ф | menzel.vet@mail.ru |
| «Мөслим районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423970, ТР, Мөслим авылы, Октябрь урамы, 44 | 85556 | 2-53-88 | Gavis.Gilemov@tatar. ru |
| «Түбән Кама районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423570, ТР, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр поселогы, а/я 27 | 8555 | 30-51-44 ф | Svetlana.Rahimova@tatar.ru |
| «Яңа Чишмә районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423190, ТР, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 68 | 84348 | 2-25-21 ф | Gulnur.Rizvanova@tatar.ru |
| «Нурлат районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423040, ТР, Нурлат шәһәре, Линейная урамы, 38 | 84345 | 2-55-30 | Valerevna.Olga@tatar.ru |
| «Питрәч районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422770, ТР, Питрәч эшчеләр поселогы, Төзүчеләр урамы, 4 | 84367 | 3-12-56 ф | Elizaveta.Valiullina@tatar.ru |
| «Балык Бистәсе район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422650, ТР, Балык Бистәсе поселогы, Шәйморданов урамы, 21 | 84361 | 2-29-72 ф | vetrs@mail.ru |
| «Саба районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422060, ТР, Байлар Сабасы ш.т.п., М. Җәлил урамы, 2 | 84362 | 2-30-93 | Taslima.Hanova@tatar.ru |
| «Сарман районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423350, ТР, Сарман эшчеләр поселогы, Профсоюз урамы, 22 | 85559 | 2-40-57 ф | sarm_vet@mail.ru |
| «Спас районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422840, ТР, Болгар шәһәре, Ленин урамы, 2а | 84347 | 3-08-41 ф | Dmitriy.Shishkin@tatar.ru |
| «Тәтеш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422370, ТР, Тәтеш шәһәре, Ветгородок, 11А | 84373 | 2-81-13 | Galina.Shemyakova@tatar.ru |
| «Тукай районы | 423806, ТР, Яр Чаллы | 8552 | 46-40-61 ф | Tukay.vet@rambler.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | шәһәре, ЗЯБ поселогы, Тимерьюлчылар тыкрыгы, 7 | | | |
| «Теләче районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422080, ТР, Теләче районы, Теләче авылы, Ленин урамы, 82 | 84360 | 2-10-39 ф | tuliachirgvo1@rambler.ru |
| «Чирмешән районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423100, ТР, Чирмешән районы, Чирмешән авылы, Ярминкә тыкрыгы, 23 | 84396 | 2-51-20 | Gulnur.Sharifullina@tatar.ru |
| «Чистай районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 422980, ТР, Чистай шәһәре, Г. Тукай урамы, 84 | 84342 | 5-17-10 ф | Dinara.Sayfulina@tatar.ru |
| «Ютазы районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423950, ТР, Урыссу поселогы, Хлебный тыкрыгы, 1 | 85593 | 2-68-62 ф | rgvo_urussu@mail.ru |
| «Яр Чаллы шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423806, Яр Чаллы шәһәре, ЗЯБ поселогы, Автомобильчеләр тыкрыгы, 8 | 8552 | 46-91-41 ф | gosvet-Chelny@mail.ru |
| «Түбән Кама шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 423577, ТР, Түбән Кама шәһәре, Спорт урамы, 12в | 8555 | 39-47-79 | Leysan.Gimranova@tatar.ru |
| «Казан шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 420073, ТР, Казан шәһәре, Шуртыгин урамы, 4 | 843 | 272-63-92 | gor.vetob@tatar.ru |

Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Форма

Шәһәр һәм район дәүләт ветеринария берләшмәсе җитәкчесенә
кемнән ___________________________
мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
_________________________________

телефон: ____________________

ГАРИЗА

Этне клиник карап чыгу һәм теркәү турында таныклык бирүегез хакында сорыйм

_______________________________________________________________________
этнең кушаматы яки идентификация номеры
_______________________________________________________________________
туган көне, җенесе, токымы.
_______________________________________________________________________
хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме яки юридик зат атамасы
_______________________________________________________________________
тору урыны яки яшәү урыны буенча теркәлү турында мәгълүматлар
_______________________________________________________________________
юридик зат урнашкан урын)
_______________________________________________________________________
физик затның фактта яшәү урыны турында мәгълүмат
_______________________________________________________________________
эт хуҗасының паспорт мәгълүматлары

Эш итү нигезе__________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эшләү вәкаләтен раслаучы документ реквизитлары)

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы

| Этнең идентификация номеры | Эт хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме яки юридик зат атамасы | Эт хуҗасының яки юридик затның фактик адресы | Этләрне теркәү турында таныклык бирү датасы | Этләрне теркәү турында таныклык алу турында имза |
|---|---|---|---|---|

Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Форма

Шәһәр һәм район дәүләт ветеринария берләшмәсе җитәкчесенә
кемнән ____________________________
мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
______________________________

телефон: _____________________

## Техник хатаны төзәтү турында гариза

Миңа бирелгән этне теркәү турындагы таныклыкта җибәрелгән техник хатаны төзәтүегез турында сорыйм.
Төзәтергә кирәкле мәгълүматлар: _________________________________
_____________________________________________________________________________
Төзәтелгән рәвештәге белешмәләр: _____________________________
_____________________________________________________________________________
Гаризага кушымталар:
1. Җибәрелгән техник хатасы булган таныклык оригиналы;
2. ________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Форма

Шәһәр һәм район ветеринария дәүләт берләшмәсе җитәкчесенә

(кемнән) ________________________________
Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, ата исеме
__________________________________

телефон: __________________________

## Таныклык дубликаты бирү турында гариза

Этне теркәү турындагы таныклыкны югалту (аның яраксызга чыгуы) сәбәпле, миңа этне теркәү турында таныклык дубликаты бирүегез турында үтенәм.
Гаризага кушымталар:
1. ___________________________________________;
2. ___________________________________________.
Эш итү нигезе:
_________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эшләүче затның вәкаләтләрен раслый торган документ реквизитлары)

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

Татарстан Республикасында
этләрне хәбәр итеп (ирекле)
теркәү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 6 нчы кушымта

Форма

Шәһәр һәм район ветеринария
дәүләт берләшмәсе җитәкчесенә
(кемнән) _______________________________
Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе,
исеме, ата исеме
________________________________

телефон: _________________________

## Таныклыкны алыштыру турында гариза

Эт хуҗасы алышынуга/ эт хуҗасының яшәү яки тору урыны үзгәрүгә/ этне теркәү турындагы таныклыкта күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәрүгә бәйле рәвештә, миңа бирелгән этне теркәү турындагы таныклыкны алыштыруыгыз хакында үтенәм.

Гаризага кушымталар:

1. ____________________________________________________________________;
2. ____________________________________________________________________.

Эш итү нигезе ___________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эшләү вәкаләтен раслаучы документ реквизитлары)

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

Татарстан Республикасында
этләрне хәбәр итеп (ирекле)
теркәү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 7 нче кушымта

Форма

Шәһәр һәм район ветеринария
дәүләт берләшмәсе җитәкчесенә
(кемнән) ________________________________
Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе,
исеме, ата исеме
_________________________

телефон: ___________________

## Этне теркәү исәбеннән төшерү турында гариза

Этнең үлеменә/ этне хайваннар приютына тапшыруга бәйле рәвештә, минем карамагындагы этне теркәү исәбеннән төшерүегез турында үтенәм
Гаризага кушымталар:
1. ____________________________________;
2. ____________________________________.
Эш итү нигезе ____________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклауны раслаучы документ реквизитлары)

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
8 нче кушымта

# Этләрне теркәү журналы

| Хайванны тасвирлау | | | | | | | | | Котыру авыруына каршы вакцинация һәм башка эшкәртүләр | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| №Т/с | Эт хуҗасының ФИА | Этне асрау адресы | Этнең идентификация номеры | Кушаматы | Туу датасы | Җенесе | Токымы | Төсе | Вакцинацияләү, эшкәртү датасы | Вакцина, серия | Ветеринария табибы имзасы | Башка билгеләр |

Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

Татарстан Республикасында этләрне хәбәр итеп (ирекле) теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне тикшереп торуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар реквизитлары

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Идарә җитәкчесе | (843) 221-77-47 | guv@tatar.ru |
| Идарә җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы | (843) 221-77-49 | Elena.Ilina@tatar.ru |
| Дәвалау-профилактика чаралары бүлеге җитәкчесе | (843) 221-75-88 | Sultan.Latypov@tatar.ru |
| Хокук бүлеге җитәкчесе | (843) 221-75-90 | Azatovich.Artur@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Адрес | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес | Сайт |
|---|---|---|---|---|
| 420014, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1 | Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе җитәкчесе урынбасары | (843) 264-76-80 | Marat.Harisov@tatar.ru | www.prav.tatarstan.ru |